


***Күәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы*** *№4 Февраль2023 ел*

**23 февраль - Ватанны саклаучылар көне, ул - көч, түземлелек, мәрхәмәтлелек һәм туган җиренә карата мәхәббәт бәйрәме.**




Мәктәбебезнең хөрмәтле ир-егетләре . Сезне барыгызны да олы бәйрәм белән котлыйбыз.
Сез булганга имин булып ата таңнар,
Тыныч-матур тормыш белән үтә айлар.
Бәйрәмегез котлы булсын, ир-егетләр,
Мәңге тыныч, имин торсын җирләр-күкләр.

***Этием- горурлыгым!***



Армия…Гади генә тоелган бу сүз эченә тирән мәгънә салынган. Яп-яшь егеттән кыю ир-атларга әверелеп кайта торган чыныгу урыны ул. Менә шундый батыр ир-егетләр арасында минем этием дә булуы - безнең өчен зур горурлык.

Әтиебез Багавиев Данис Римхәт улы 1991 елда хәрби хезмәткә алына. Хәрби хезмәт юлын ул, Азов диңгезе белән Кара диңгез кушылган урында урнашкан, герой шәһәр Керчьтә башлый. Ул анда алты ай белем ала, ягъни «учебкада» була. Башта самолетларның двигатален кабызу агрегатларында эшләргә өйрәнәләр. АПА - 5 (Аэродромный пусковой агрегат) дигән махсус кабызу машинасында эшләргә өйрәтәләр. Аннан соң, эти Марий Эл республикасы Йошкар Ола да хезмәт итә, ул хәрби аэродромда эшли. Самолет һәм вертолетларны техник хәзерлеген тәэмин итеп карап тикшереп торалар. Әтинең бүген дә армия истәлеге итеп күп санлы фотолары һәм куен дәфтәре - блокноты саклана. Анда истәлекләр, шигырьләр, җырлар һәм дуслары турында язылган язмалар һәм адреслар саклана.

Ул 1993 елның 12 октябрендә исән-сау туган авылына әйләнеп кайткан. «Армиядән чын ир егет булып кайтасын» , - ди этием.
Армиядә төшерелгән күп санлы фотографияләргә карап, этиемнең яшь чагын күрәм, яшь егет вакытын күз аллыйм. Дөньялар тыныч булсын, бөтен илнең балалары да безнең кебек тыныч йокыларын йоклап, сөенә-сөенә мәктәпләренә барсын, аларның бары тик шат авазлары гына яңгырап торсын иде. Мәктәптә хәрби патриотик ай кысаларында очрашулар уздырыла, күргәзмәләр оештырыла, конкурслар уза. Проект эшләре дә эшлибез. Игелекле эшләребез дәвамлы булсын. Багавиев Адель ,8 сыйныф

**Минем эти- үрнәк кеше!**

Минем этием Садриев Рафис Армия сафларында 2006 -2008 елларда хезмәт иткән.2006 нчы елда ул Пермь шәһәренең Гамова поселогында 6 ай укып сержант дәрәҗәсен ала. Аннан соң этиемне Водкинск шәһәренә хезмәт итәргә җибәрәләр. Алга таба этиемне Казан шәһәрендә урнашкан пороховой заводын сакларга куялар.Ул үзенең тырышлыгы белән старший сержант дәрәҗәсенә җитә. Мин сеңлем Айгөл белән этием өчен бик горурланам.Ул безгә нык терәк.

**Садрева Айсинә, 4 сыйныф**

Без, 1нче сыйныф укучылары, тарихи әйберләр куелган күргәзмә карадык.Укытучы Садриева Алия апа безгә солдатларның кыр сумкасы,су эчә торган флягасы, ботка ашый торган котелогы,сапёр көрәге турында сөйләде.



Ул безне кара тостәге “Хәтер” китабы белән таныштырды .Бу китапта сугышта катнашучы бабайларыбызның исем-фамилияләре язылган. Бабайларыбыз без матур тормышта яшәсен өчен көрәшкәннәр.Без алар белән горурланабыз.
Матур һәм аңлаешлы чыгышы өчен Алия апага зур рәхмәт.

**Халитова Иркә, 1 сыйныф**

**Илебез турында мәкальләр**

1. Илсез кеше - телсез сандугач.
2. Сыерчык диңгез артына китсә дә, үз туган оясына кайта.
3. Һәр гөл үз сабагында чәчәк атар.
4. Туган илнең кадерен читтә йөрсәң белерсең.
5. Туган туфракка баскан эз суынмый ,

**Бабам да солдат булган...!**



Минем карт бабаем Галимуллин Газимҗан Галимулла улы 1923 нче елның 9 сентябрендә Арча районы (элеге Әтнә районы) Дусым авылында туган. Башлангыч белемне үз авылында, 7 нче сыйныфны Күәм мәктәбенә йөреп ала. 7 нче сыйныфны тәмамлагач, эшли башлый: бабай ат җигә, бәрәңге төяп Алатка йөри, урманнан утын алып кайтып, Олы Әтнәдәге оешмаларга өләшә.

1939 елны олы абыйсының фин сугышында һәлак булу хәбәре килә. Озаклямый Бөек Ватан сугышы башлана. 1942 нче елның 1 маенда бабайны кордашы Йосыфҗан белән сугышка алалар. Ижевск тирәсендәге урманда махсус өйрәнүләр узалар. Авылдашы белән юллары аерыла. Газимҗан бабайны иптәшләре белән поездга утыртып, Ленинградка җибәрәләр. Аларны су аркылы пароход белән Ленинградка алып керәләр.Снарядлар шартлый, урман эченә кереп сакланалар. Землянкаларга урнашалар. Көндез окоп казыйлар, төнлә сакта торалар.

Ашау-эчү такы-токы гына: ярты котелок ботка, 600 грам икмәк биргәннәр. 1942 нче елның 18 августында ул яралана, күзенә снаряд кыйпылчыгы эләгә. Ленинград үзәгендәге бер госпитальдә 2 ай дәвалана.Яңадан сугышка әйләнеп кайта. Көчле бәрелешләр була. 1943 елда бабай яңадан яралана, уң аягына снаряд кисәге керә.Урмәләп, урман эченә керә, авызы яраланган бер сугышчы белән бер-берсенә ярдәм итешеп, немецлар калдырып ачкан землянкага кереп түнәләр. Икенче көнне санитарлар шәһәргә госпитальгә илтәләр. Аягына операция ясыйлар. Савыккач, эшче командага озаталар.

Блокаданы өзгәч, фашистларны куып, Латвия, Эстония җирләренә керәләр.

Әле моның белән бабаем өчен сугыш тәмамланмый. Газимҗан бабайны Японияга каршы сугышка җибәрәләр. Башта бабай Монголиягә эләгә, аннан соң Кытайга. Туган ягына бабай 1947 елның 8 мартында гына кайта.

Минем бабаема Бөек Ватан сугышында катнашканы өчен, туган җирен фашистлардан яклаганы өчен бик күп медальләр бирелгән. Шулар арасыннан бабай өчен истәлеклеләре: «За оборону Ленинграда», «За боевые заслуги», «За победу над Японией», «Письмо благодарности от Сталина». Барысы бабайның 19 медале бар.

Ләкин хәзерге вакытта бабай исән түгел, мин аңа бу тыныч , рәхәт тормышыбыз өчен бик зур рәхмәтлемен.

Ханафиев Ильвир ,9 сыйныф

**Эти дә солдат булган...**

Бу җырның сүзләре нәкъ менә безнең гаиләгә багышлап язылган дисәк тә була. Минем бабаем да, этием дә Армия сафларында хезмәт иткәннәр.

Минем бабаем 1984 нче елны көз көне армиягә алына.Ул Венгриянең Будапешт шәһәрендә хезмәт иткән.Алар 2 этажлы казармада торганнар. 3 ай шоферлар хәзерләү сборында булганнар.Ул анда шофер хезмәте үтәгән. Иртә белән сәгать 6 да торганнар, 3 км чабып кайтканнар. Аннан юынып иртәнге ашны ашаганнар. Шуннан гаражга барып машиналар ремонтлаганнар. Кичке аштан соң ял иткәннәр. телевизор караганнар. Кич белән сәгать 10 да йоклаганнар. Ял көнендә клубка киноларга барганнар. Шулай итеп 2 ел вакыт үтеп тә киткән.1986 нчы елны бабаем армиядән кайткан.

Мин бабаемны да, этиемне дә Ватанны саклаучылар көне белән тәбрик итәм.

**Нәҗмиев Риназ, 3сыйныф**

## Гаиләләрдә -Ватанны саклаучылар!

23 нче февраль – Ватанны саклаучылар көне. Минем әтием дә, абыем да Ватанны саклаучылар сафында булган. Алар без тыныч тормышта яшәсен өчен армия сафларында хезмәт итеп, илебез чиген сакладылар.

Әтием Пенза шәһәрендә хезмәт иткән, ә абыем Хабаровск шәһәрендә пехотачы була. Алар анда төрлесен күрә, төн йокыларын йокламаган вакытлары да күп була. Шуңа күрә мин Ватанны саклаган ир-егетләрне, әти-абыйларны хөрмәт итәм. Барлык Ватанны саклаучыларны бәйрәмнәре белән тәбрик итәм.

**Гәрәева Зилия, 2 сыйныф .**

Минем әтием Фазуллин Рәдиф Рәис улы. Ул 1987 нче елның ноябрь аенда Совет Армиясе сафларына алына. Ул хәрби диңгез флотына эләгә. Беренче биш айда Анапа шәһәрендә хәрби укуларда була. Ул рулевой моторист һөнәрен үзләштерә. Аларны зур көймәләрне суда йөртү кагыйдәләренә өйрәтәләр. Шулай ук әтием хәрби уставны да өйрәнә. Хәрби укулар беткәч Архангельск шәһәренә җибәрәләр. Алар анда хезмәт иткәндә чит ил көймәләрен озатып йөриләр. Әтием хезмәт иткәндә төрле кыенлыклар да булгалаган. Күмәк көч, тырышлык, көчлелек аркасында алар кыен хәлләрдән тиз чыкканнар. 1990 нчы елнын октябрь аенда хезмәт срогын тутырып туган авылына кайта.Мин әтием белән горурланам.

**Фазуллин Раяз 4 сыйныф**

## Илебезнең чын патриотлары булырбыз!

Күәм урта гомуми белем мәктәбендә патриотик айлык бара. 15 нче февраль көнне иртәнге 7.45-8.20 кадәрле аралыкта “Парламент дәресләре” булып үтте. Укучыларга гражданин, Ватан алдында торган бурычлар, үзебезнең хокукларыбыз, закон, гаилә, әхлак тәрбиясе бирелде. Аннары хәрби өлкәдә хезмәт итүче яхташ егетләребез Сөнгатов Марат Марсель улы, Галимуллин Тимур Таһир улларының хәрби хезмәт өлкәсендә булган вакыйгалар белән танышып үттек. Бу чараны Сөнгатова Голнара Зөлкар кызы оештырды. Садриева Алия Габдулла кызы өстәмә мәгълүматлар биреп китте.

Әфган чигеннән Совет гаскәрләре чыгарганга 34 ел вакыт үтеп китү уңаеннан “Әфганстан-йөрәк ярасы” дигән тема астында Әфган Ветераннары белән очрашу булып үтте. Очрашуда 5-11 сыйныф укучылары катнашты.Килгән кунакларны 7 нче сыйныф укучылары каршы алды. Әфганчылар үзләренең тирән хатирәләре, патриотик тәрбия, күтәренке рух, хәрби хезмәт һәр егеткә хас булырга, һәрберебез батырлык кылучы укучылар булуыбыз турында аңлаттылар. Кәбиров Ленар, Касыймов Раил, Тухфатуллин Булат абыйларның теләкләре, хатирәләре безне тормышны яратырга чакырдылар.

15 нче февраль Муса Җәлилнең туган көне уңаеннан искә алу кичәсе булып китте. Чарада сәнгатьле итеп язучының шигырьләре, җырлары тыңлап үтелде. Һәр сыйныф укучысы да актив булырга тырышты. Башлангыч сыйныф укучысыннан алып, зур сыйныф укучыларына кадәрле тәрбия сәгатен, чараны үз иттеләр.

Халыкара туган телләр көне дә читтә калмады. Рус телчеләре тарафыннан сәнгать, рус әдәбияты , башка телдә аралашучы милләт вәкилләренендә Бөек Ватан сугышында катнашып, Совет илен яклаулары турында белдек.

“Аҗаган- 2023” патриотик чара 7-11 сыйныфлар арасында үтте. Һәр сыйныф үзен хәрби яктан сынап карады. Аннары Сугыш чоры җырлары астында маршировка үттек.Төрле командалар башкардык. Шулай ук 11 нче февраль көнне Студентлар белән очрашу булып үтте. Мәктәпне тәмамлап чыккан һәр студент үзенең уку йорты , нинди һөнәр иясе булачагы турында сөйләде. Мин патроит- чонки туган телемне, туган ягымны яратам, укыткан укытучыларыма рәхмәтемне җиткерәм дигән сүзләрне ишетү һәрбер укучыга барып ирешге, укытучыларыбызга яшәү дәрте өстәде. Чарада кызыклы, мавыктыргыч ярыш, күңелле ял сәгате оештырылды.

23 нче февраль- Ватанны саклаучылар көне! Шул уңайдан һәр сыйныф ир-егетләребезне котларга дип видео сюжетлар, бәйрәм чаралары, истәлекле бүләкләр әзерләдек.

Февраль аенда үткәрелгән һәрбер чара ул безнең сыйныф җитәкчеләребезнең, үзебезнең зур хезмәтебез. Һәр укучы патриот-һәр укытучы тугъры юл күрсәтүче! **Зөхрә Ганиева 7 сыйныф**

**Нәрсәдә икән сәбәп?**

| | |
|---|---|
| Булса унбиш метр булыр | Безнең авыл күпереннән |
| Ике ярның арасы. | Чыгасың ике сәгать. |
| Шул араны машинада | Серен әйтмим. Син дә уйла: |
| Ике сәгать барасы. | Нәрсәдә икән сәбәп? (уйла, тап) |

## Данлы еллар кайтавазы...



Бу сүзләрне ишетүгә, күз алдына илебез данын яклап көрәшкән яшь егетләр һәм кызлар килеп баса. Аларның мәңгелек даны безнең йөрәкләрдә саклана. Бу данлы еллар, данлы батырлыкны без онытырга тиеш түгелбез. Шул максаттан чыгып, мәктәбебездә ел саен диярлек күргәзмәләр оештырыла. 20 нче февраль көнне “Мои родные герои” дигән темага күргәзмә узды. Без 5 нче сыйныф укучылары да бу акциягә катнаштык. Үзебезнең гаиләбездәге батырлык үрнәге булган якын кешеләребезне барладык. Бар алар, әлбәттә. Аларның фотоларын, орден медальләрен алып килдек, истәлекләрне күргәзмәгә куйдык. Һәр сыйныф бу күргәзмәләрне кызыксынып карады. Батырлык үрнәге булган кешеләребез белән горурландык. 23 нче февраль – илне саклаучылар көне уңаеннан бу күргәзмә безгә патриотизм хисе өстәде, туган илгә мәхәббәт, якыннарың белән горурлану хисе уятты. Үскәч, без дә илебезне саклаучылар булырбыз, батырлыклар эшләрбез дип ышындырасы килә.

**5 сыйныф укучылары**

## Дәү әтиле булу зур бәхет!

Минем Дәү әтием Гатауллин Мансур Сафа улы 1965- 1967 нче елларда Мәскәү өлкәсе Балашиха шәһәренең 3406 хәрби частендә хезмәт иткән.



Армиядә аңа рядовой званиясе бирелгән. Дәү әти армиядә шофёр хезмәтен үтәгән һәм бик күп еллар әлеге хезмәтенә тугры булган. Дәү әти үзенең армиядә хезмәт иткән вакытларын гел безгә сагынып сөйли.

2018 елда безгә Дәү әти белән бергә хезмәт иткән иптәше Төрекмәнстаннан кайтты. Ул дәү әтине 50 елдан соң эзләп тапкан. Бу бик дулкынландыргыч вакыйга булды. Чәчләренә күптәннән чал кунган бабайларның күзләрендә яшь, сагыну катыш истәлекләр яна иде. Күпме еллардан соң очрашып, ике дусның истәлекләрен тыңлау безгә бик зур тәрбия бирде.

Без Дәү әтиебез белән горурланабыз, хөрмәт итәбез, яратабыз. Ул биргән киңәшләр безне гомер буена озата барыр . Аның тырышлыгы, сабырлыгы турында китап язып булыр иде. Рәхмәт сиңа Дәү әти барысы өчен дә. Безне куандырып озак еллар Дәү әниебез белән матур итеп яшәргә язсын!

**Гатауллина Лилия, 6 сыйныф**

**Яңалыклар**

- Бөек рус җырчысы Россиянең халык артисты Федор Шаляпинның тууына 150 ел (1873-1938)
- Шагыйрь, педагог Фәрит Ибраһимовның тууына 130 ел (1893–1943)
- Шагыйрә Гөлзада Әүхәди кызы Бәйрәмовага 60 яшь (1963)
- Җырчы, Татарстан Республикасының халык артисты Галина Казанцевага 70 яшь (1953)



**Февраль аенда хөрмәтле укытучыларыбыз Гөлгенә Рафис кызының, Энҗе Рахимҗан кызының туган көннәре. Аларга зур уңышлар, сәламәтлек, бәхетле тормыш, тынычлык телибез!**

**Тапкырлар тапмый калмас (рус телендә)**

